Республика Татарстан
Совет Чукмарлинского сельского поселения Сармановского муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Чукмарлы авыл җирлеге советы

РЕШЕНИЕ
2016 ел, 1 февраль

КАРАР
№ 7

Чукмарлы авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 ст. 1 п., Чукмарлы авыл җирлеге Уставының 11 ст. нигезендә Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге Советының 2016 елның 25 гыйнварында кабул ителгән карары нигезендә № 6 «референдум үткәрү инициативасы турында», Чукмарлы авыл җирлеге Советы хәл итә:
1. 2016 елның 20 мартына Чукмарлы авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
"2016 елда Чукмарлы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, 200 сум күләмендә үзара салым акчасын кертүегез һәм алган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүегез белән килешәсезме?:
- җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру ,чапкыч сатып алу, су башнясын коймалау, урамнарны яктырту;
- Ялны оештыру өчен шартлар тудыру (музыка аппаратурасы, музыкаль-яктылык җиһазлары сатып алу);
- көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чар җыюны һәм чыгаруны оештыру.

«ЮК» «ӘЙЕ».

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән 5 көн эчендә халыкка игълан итәргә.
4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Чукмарлы авыл җирлеге башлыгы: Мостафин Ф. А.